| СОВЕТ ТАТАРСКО-ДЮМ-ДЮМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР-ДӨМ-ДӨМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от 14 июня 2017 г с. Татарский Дюм-Дюм № 79

**Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге Советының «Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында»2007 ел, 12 нче июль, 12 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы нда җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 30.12.2005 елдагы 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге Советы

Карар:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Алабуга муниципаль районы Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге Советының 2007 ел, 12 нче июль, 12 нче номерлы карары белән расланган гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында" 2007 ел, 12 нче июль, 312 нче номерлы карары:

1.1.Нигезләмәнең 1 статьясындагы 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Герб таныклыгына һәм туу, никах, аерылышу, ата булу, үлем таныклыгына кул кую хокукына ия булды.

1.2. Нигезләмәнең II статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Башкарма комитет җитәкчесе:

1. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык бланкларының сакланышын тәэмин итә.

2. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеге белән идарә итү өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты ГХАТ органнарына граждан хәле актларын теркәү язмаларының беренче һәм икенче нөсхәләрен тәкъдим итә.

3. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу белән бәйле мәгълүматларны Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеге белән

идарә итү өлкәсендә вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыра.

4. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торуда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына кирәкле ярдәм күрсәтә".

1.3. Нигезләмәнең V статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен авыл җирлеге башкарма комитетына гражданлык хәле актларын теркәү турында таныклык бланклары, махсус компьютер программалары тапшырыла.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән Граждан хәле актларын теркәү турында таныклыклар бланкларыннан һәм махсус компьютер программаларыннан тыш, Татарстан Республикасы милкендә булган матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә Башкарма комитетка түләүсез файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген эшләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында Карар кабул итү мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеге белән идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Җирлекнең башкарма комитеты муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә аңа тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә үз матди ресурсларыннан файдаланырга хокуклы".

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Район башлыгы урынбасары А. З. Хуҗин